# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2026 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**22.11.2025** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 маендагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы 45-ФЗ Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында үткән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Халык җыены карар итте:

1. Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2026 нчы елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләр, 80 яшьтән өлкән гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә 2023 елдан контрактлар төзегән гражданнарга 90% ташлама каралган.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма жайланмасы кую, төзәтү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сосна авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов